ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
КИЧКЕТАНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АГРЫЗСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
КИЧКЕТАҢ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

22.10.2019 Кичкетаң авылы номер 11

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы бюджетыннан алына торган башка бюджетара трансфертлар акчалары исәбеннән гамәлгә ашырыла торган чыгымнар юнәлешен раслау турында

Бюджет турындагы карар нигезендә һөнәри керемгә салым буенча салым потенциалы үсешен стимуллаштыру максатыннан, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Кичкетаң авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы бюджетыннан авыл җирлегенең җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен алына торган башка бюджетара трансфертлар акчалары исәбеннән гамәлгә ашырыла торган чыгымнарны «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясындагы 19 пункты, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 15 статьясындагы 19 пункты (җирлек территориясен төзекләндерүгә юнәлдерелгән чаралар) нигезендә расларга.

2. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Кичкетаң авыл җирлеге Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы бюджетыннан алына торган башка бюджетара трансфертлар акчалары исәбеннән гамәлгә ашырыла торган чыгымнарның юнәлешен раслау турында» 2019 елның 2 октябрендәге 9 номерлы карарны үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны Кичкетаң авыл җирлеге мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән игълан итәргә, Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында Әгерҗе муниципаль районы сайтында http://agryz.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru урнаштырырга.

5. Карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкчесе З.Р.Нуриев